# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ЯҢА БҮЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«29» январь 2024 ел Яңа Бүләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәне 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы 3 өлеше 15 пункты нигезендә Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 1 февраленнән Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 һәм 2 кушымталар нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегенең «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2023 елның 16 февралендагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.С. Сагетдинов

Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварендәге 1 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 4268 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмне□ мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1674 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2428,20 |
| **Барлыгы:** | 8370,20 |

Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 29 гыйнварендәге 1 номерлы карарына 2 кушымта

2024 елның 1 февраленнән ТР Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кафенгә төрү | 1339 |
| 3. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү һәм китерү | 3013 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмне мәетен зиратка алып бару, ритуаль билгеләнештәге предметларны китерү) | 1674 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2344,20 |
| **Барлыгы:** | 8370,20 |